СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**21.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 185**

Зеленодольск шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча ревизия комиссиясе вәкаләтләрен «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2015 елның 9 февралендәге 306 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе Кадыйрова С.В. мәгълүматларын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча ревизия комиссиясе вәкаләтләрен «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2015 елның 9 февралендәге 306 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «ревизия комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Карар преамбуласында «ревизия комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. Карарның 1 пунктында «ревизия комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкаруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү методикасын 2 нче кушымтада каралганча расларга».

3. Кушымтада каралганча, карарны 2 нче кушымта белән тулыландырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат (https://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск шәһәре Советының
2025 елның 21 мартындагы
185 номерлы карары белән расланды
Зеленодольск шәһәре Советының
2015 елның 9 февралендәге
306 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен үтәүгә тапшырыла торган бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү методикасы**

Вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга (С) Зеленодольск шәһәре бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына чираттагы елга бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме түбәндәгечә билгеләнә:

С = Зр + Зи

Зр - эш күләмнәрен башкаруга чыгымнар

Зи - башка чыгымнар.

Эш күләмнәрен башкару чыгымнары түбәндәгечә билгеләнә:

Зр = Рб * Кр

биредә Рб - база чыгымнары;

Кр - эш күләме коэффициенты.

Исәп-хисап өчен база чыгымы булып чаралар үткәрү өчен районның Контроль-хисап палатасы хезмәткәре исәпләгән хезмәт өчен түләү фонды тора.

Рб = (ФОТ + Н)

биредә ФОТ - ЗМР Контроль-хисап палатасының бер хезмәткәренә хезмәт өчен түләүнең еллык фонды;

Н - хезмәт хакына карата түләүләр.

**Зеленодольск муниципаль районы бюджетына ЗМР җирлекләреннән тышкы финанс контроле өлкәсендәге вәкаләтләрне тапшыруга субвенцияләрне исәпләү**

(бюджет проектларына экспертиза ясау һәм бюджетлар үтәлеше турында еллык хисапларны тышкы тикшерү буенча эшләр башкару өлешендә).

Субвенцияләрне исәпләү аудиторларның бәяләмә әзерләүгә эш күләмен, хезмәт чыгымнарын исәпкә алып башкарыла:

- бюджет үтәлеше турындагы хисапка, җирлек бюджеты проектына бәяләмә әзерләүгә - көнгә 25 кеше